# Фәрхетдинова Галия Габдрахман кызы



Фәрхетдинова Г.Г. Баулы районы Татар Димскәсе авылында 1948 нче елда туа. Баулы урта мәктәбен тамамлаганнан соң Казан Дәүләт университетының тарих филология факультетында белем ала.

1980 нче елдан алып лаеклы ялга чыкканчы, Мөслим урта мәктәбендә тарих һәм җәмгыять белеме фәннәрен укыта һәм укыту эшләре буенча директор урынбасары булып эшли. Ул Баулы урта мәктәбендә укыганда да университетта белем алганда да бик актив була, җирле газетага мәкаләләр яза, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша. Студент елларында мөслимлеләр – Марсель Бакиров, Флүс Латыйповлар белән берлектә факультетның бишәр метрлы "Әллүки" газетасын чыгаралар. Җыр сәләтен үстерү максатыннан, Сара Садыкова һәм Ирнес Рәхимуллин җитәкләгән хорларга йөри, мәктәптә актерлык осталыгы да кирәк булыр дип театр студиясенә йөри. "Ир-атларга гына түгел, укытучыга да 70 төрле һөнәр иясе булырга, балаларга белем генә түгел, тәрбия дә бирергә, аларның сәләтен күтәреп алып, аны үстерергә тиеш"- дип саный ул.

Галия Габдрахмановна укытучы һөнәрен сайлап, гомерен шуңа багышлаганга һич тә үкенми. "Укытучы иң беренче чиратта, үз фәнен тирән белергә, белемен төпле һәм кызыклы итеп балаларга бирергә тиеш булса, икенчедән балаларны чын күңелдән яратырга аларны тигез күрергә тиеш. Шул вакытта гына укычылар сине хөрмәт итәрләр, ә фәнneңне яратырлар",- ди ул.

Белем бирү өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле хезмәт күрсәткәне өчен ул РСФСР мәгариф министрлыгының һәм ВЛКСМ өлкә комитетының почет грамотасы белән бүләкләнә. Татарстан укытучыларының Vнче Республика

съездына делегат итеп сайлана. Россия Федерациясенең халык мәгарифе отличнигы исеме бирелә. “Хезмәт ветераны” тамгасына лаек була.

“Укытучы өчен иң зур бүләк һәм иң зур мактау – үзе укыткан балаларның онытмавы, аларның рәхмәте һәм хөрмәте. Әле күптән түгел урта мәктәпне 1985 нче елда тәмамлаган биш паралель класс укычылары ишек алдын тутырып килеп керделәр, һәрберсе тормышка үз-урыннарын тапкан, көләч йөзле , инде өлкәнәя барган укучыларымның кочаклап алып, рәхмәт әйтүләрен, хәлемне сораулары бернинди исем дә, мактау кәгазе дә алыштыра алмый”-дип искә алды Галия Габдрахмановна.

Лаеклы ялга чыккач та, ул актив тормыш позициясен дәвам итә. Ветераннарның “Сүнмәс дәрт” клубына йөреп, тамашычыларны матур җырлары белән сокландыра. Район ветераннар хәрәкәтенең актив әгъзәсе буларак, Бөтенроссия пенсионерлар союзының Мөслим бүлекчәсендә, аннан соң район ветеран советында рәис урынбасары булып эшли, мәктәпләргә очрашуларга йөри, балалар белән кызыклы әңгәмәләр уздыра, китапханәдә уздырыла торган чараларда катнаша. “Авыл утлары” һәм “Татарстан яшьләре» газеталары белән хезмәттәшлек итә, аларда аның кызыклы язмалары әледән-әле басылып тора.

Галия Габдрахманова укытучылар династиясенен дәвам итеп, үзе дә ике педагог тәрбияли. Улы Айнур Тойгелде төп гомуми белем бирү мәктәбендә директор булып эшли, кызы Резеда Казанда яши, мәктәптә тарих һәм җәмгыять белеме фәннәрен укыта.